**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.02.2021 № 92

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 21 декабрендәге 1061 номерлы карары белән расланган социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 21 декабрендәге 1061 номерлы карары белән расланган социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча

муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.6. пунктта:

«йорт кенәгәсеннән өземтә» сүзләрен «яшәү урыны буенча теркәү турында белешмәләр - Россия Эчке эшләр министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«5) гариза бирүче гаиләсенең барлык 14 яшькә җитмәгән әгъзалары өчен туу турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

6) Мөрәҗәгать итүче һәм/яисә аның гаилә әгъзалары өчен никахны теркәү турындагы таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

7) Ата булуны билгеләү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

8) Никахны өзү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

9) Опека билгеләү турында белешмәләр - Россия Федерациясе Пенсия фонды»;

3.4.1 пунктында.:

«йорт кенәгәсеннән өземтә» сүзләрен «яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«4) бала туу турында таныклык;

5) никахлашу турында таныклык;

6) ата булуны билгеләү турында таныклык;

7) никахны өзү турында таныклык;

8) опека билгеләү турында белешмәләр.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары М.Х.Хабибулловага йөкләргә

Җитәкче Р.М. Заһидуллин